УкучыларныңIIТөбәкараукулары

“Тау ягының тарихы, мәдәнияты һәм рухи байлыгы”

# Якташларыбызның лаеклы исемнәре буыннар хәтерендә

Башкарды: Яшел Үзән шәһәре
А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицейның
10 нчы Б сыйныф укучысы Низамов Илһам

Җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Гизеева Гөлфия Искәндәр кызы

2020 нчы ел

**Эчтәлек**

I. Кереш

II. - Төп өлеш.

- Тау ягы халыкының уңышлары.

- Апас һәм Кайбыч районының данлыклы кешеләре – халык хәтерендә.

III. Йомгаклау.

IV. Кулланылган әдәбият.

Кемнәрдер     әйтсә- әйтсеннәр,

Караңгы як дисеннәр

Яктырта безнең тарихны

Нуры сүнмәс кешеләр

Ш.Галиев

**Кереш**

Татарстанга караган, чал тарихлы урта Иделнең уң ягына урнашкан районнарны Тау ягы- Җәбәлстан дип атыйлар.Аңа Апас, Кайбыч, Кама Тамагы, Югары Ослан, Яшел Үзән районнары, Марий Эл республикасының Таулы мари районы һәм Чувашстан республикалары керә.Дөньяда матурлыгына сокланып туймаслык илләр- җирләр күп. Әмма без аларны күбрәк табигый гүзәллегенә карап түгел, ә әдәбият- сәнгатькә, аерым фәннәрне, җитештерү тармакларын үстерүгә өлеш керткән олуг шәхесләре буенча беләбез. Халкыбызның олуг шәхесләре бик күп. Ләкин иҗатлары, кылган гамәлләре белән макталып, берничә буын хәтерендә җуелмыйча яшәүчеләре сирәктер.

Бу эшемнең **төпмаксаты һәм бурычлары**: туган ягыбызның гүзәл, кабатланмас,тырыш, киң күңелле һәм кунакчыл кешеләре, аларның күркәм эшләрен күрсәтүдән гыйбәрәт. Бу теманы Тау ягының ике районы мисалында яктыртырга уйлыйм.Беренчедән, алар күршеләр, икенчедән, Апас һәм Кайбыч районнары егерменче гасырның алтмышынчы елларында бергә берләшеп,егерме тугыз ел (1964- 1993) Апас районы исеме белән аталып йөргәннәр.

## Төп өлеш

Тау ягы халкының тормыш- көнкүреше,шөгыле, гомумән археологиясе шактый уңышлы өйрәнелгән. Аны өйрәнүдә галим-архелоглар П.И.Кротов, Н.Ф.Калинин,В.Ф.Смолин,А.Х.Халиков, А.П.Смирнов, соңгы елларда А.А.Борһановлар үзләреннән зур өлеш керттеләр. Дәвеш авылы янында,Зөя елгасының уң як яр буенда урнашкан “Кыз тавы” һәм “Каравыл тавы”нда үткәрелгән археологик эзләнүләр тау ягы халкының игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүләрен раслыйлар.Тау ягы халкы, аның шәхесләре,республикабызның башка халыклары кебек,тарихыбызның иң кискен, иң авыр, иң җаваплы вакытларда һәрвакыт үзен уңай яктан күрсәткән моны дәлилләү өчен бер генә мисал китерәм. Сталинград өчен канкойгыч сугышлар барган вакытта Свияжск –Ульяновск тимер юлын төзү турында СССР дәүләт Обороны Комитеты карары 1942 нче елның 15 нче февралендә кабул ителә. Эчке эшләр халык коммиссариатына Свияжск –Ульяновск тимер юлы проектын ясау һәм юлны төзү,Сталинград өчен канкойгыч сугышлар барган вакытта халык коммиссариатына Свияжск –Ульяновск тимер юлы проектын ясау һәм юлны төзү бурычы куела. 1942 нче елның декабрендә поездлар хәрәкәтен ачу планлаштырыла.Әлеге максатны гамәлгә ашыру ниятеннән Эчке эшләр халык комиссары Л. Берия боерыгы белән Баш тимер юл төзелеше лагерьлары идарәсенең БАМ проекты Свияжск экспедициясе оеша. Эшкә репрессияләнгән Идел буе немецлары җәлеп ителә. Тау ягыннан җирле халык та хезмәткә тартыла. Төзелештә 31556 кеше катнаша. Алар карамагында 17 экскаватор,392 “ЗИС-5” автомашинасы,20 трактор,1082 ат була. Вакытлыча 14 электр станциясеэшли. Төзелеш мәйданына 7х21 метр зурлыктагы 481 брезент палатка урнаштырыла. 19 мең тоннадан артык рельслар354 мең 159 шпалга беркетелә.Свияжск –Ульяновск арасында хәрәкәт 1942нче елның27нче сентябрендә,вакытыннан ике ай алда ачыла,Сталинградка зур ярдәм килә.Башта тәүлегенә 12шәр поезд йөри. Алар сәгатенә уртача 24-34 километр тизлек белән хәрәкәтләнә. Кильдураз,Буа,Цильна станцияләре һәм Ходяшево, Ключи, Борындык, Лаишевка разъездлары ачыла. Нәтиҗәдә,Бөек Ватан сугышының хәлиткеч елында, юл Сталинградка кадәр алып бара. Тау ягы кешеләренең фидакарь хезмәте бу төзелештә дә ачык чагыла.Шундый шәхесләребез булганда,халкыбыз,аның тарихы, мәдәнияты беркайчан югалмас, лаеклы

исемнәре буыннар хәтерендә мәңге сакланыр. Чөнки халык хәтере- мәңгелек!

## **Советлар Союзы Геройлары**

**Апас районыКайбыч районы**

1. Абзалов Рем 1. Кузьмин Михаил

2. Горбунов Дмитрий 2. Кошкин Андрей

3.Кәримов Салават 3.Федоров Иван

## **Социалистик Хезмәт Геройлары**

1.Садовников Владимир1.Гарифуллин Барый

2.Кәлимуллина Мәгъсүмә2.Кәлимуллин Рифкәт

3.Никитин Семен

4.Мәликова-Шәфигуллина Әминә

5.Галиев Гайфетдин

## **Хезмәт Даны Орденнарының тулы кавалерлары**

1.Аверьянов Василий 1.Платонов Василий

2.Субботин Иван

Тау ягы халкыбызның бәһасез рухи хәзинәсен баетуга зур өлеш керткән әдәбият –сәнгать әһелләрен күп биргән як.Алар арасында язучылар,шагыйрьләр, актерлар, җырчылар... Хәер, барысын да санап бетерерлекме?Шулай да кайберләре турында беркадәр мәгълүмат бирүне кирәк дип саныйм.

## Язучылар һәм шагыйрьләр

1.Крымов  Мансур  1.Зариф Бәшири

2.Вәлидов Садрислам 2.ӘбрарСәгыйди

3.Шәфигуллин Вәли 3.Әбрар Шамин

4.Харисов Габдуллаҗан  4.Гали Хуҗиев

5.Камалетдинов Әгъзам 5.Мәгъсүм Хәкимов

6.Гали Хуҗиев

7.Шәүкәт Галиев

8.Хәбир Ибраһимов

## Опера сәхнәсендә данга ирешкәнҗырчылар

1. Сара Садыйкова 1. Галия Кайбицкая

2.Фәхри Насретдинов2.Лидия  Әхмәтова

## Татар театр сәнгатенә армый-талмый хезмәт итүче шәхесләр

1.Алсу Гайнуллина 1. Гөлчәчәк  Гәйфетдинова

2. Илсия Төхфәтуллина

3. Илдус Габдрахманов

4. Әмир Камалиев

Җыр–музыка сәнгате-үзенә бер дөнья. Монда да Тау ягы кешеләре лаеклы урын алып торалар.**Атаклы композиторларыбыз**: **Әгъзам Фәттах**,**Рәшит Кәлимуллин** исемнәрен атарга мөмкин.Тау ягының матурлыгын, күркәмлеген моңнары аша ерракларга таныткан җырчылар:**Гүзәл Маликова**,**Илсур Сафин**,**Фердинанд Сәләхов.**

Безнең  мәктәптә  дә Тау ягының Апас районы Чатбаш  авылында туып үскән югары белемле укытучы эшли.Ул- Садриев Әхәт Шәйхи улы. Аңа 81 яшь. Шуның 61 елын Әхәт абый  мәктәпкә, балалар тәрбияләүгә

багышлый. Яшел Үзән шәһәренең хөрмәтле гражданины, шәһәр һәм муниципаль район алдындагы хезмәтләре өчен 2011нче елда медаль белән бүләкләнә. Әхәт абый Каюм Насыйри исемендәге (1997),профессор Мөхәммәт Гайнуллин исемендәге (2005), Михаил Ломоносов исемендәге (2005) бүләкләр лауреаты. Татарстанның Атказанган укытучысы (1990). Ул хезмәттәге уңышлары өчен Европа-Азия илләренең гуманитар Академиясе, “Юнеско”ның дөнья халыклары мәдәнияты институты тарафыннан XXI гасыр укытучысы дипломы һәм алтын медале белән бүләкләнгән .(2011) Россия Хәрби-тарихы Фәннәр Академиясе әгъза –корреспонденты.

1990нчы елдан башлап, 2016нчы елга кадәр25 ел дәвамында,Әхәт Шәйхи улы Татарстан Республикасының 1941-1945 нче елларда Бөек Ватан сугышында Һәлак булган һәм хәбәрсез югалганнарга багышлап 28 том, “Алар илгә җиңү алып кайтты” исемле 35 том,Татарстанда гәепсезгә гаепләнеп хөкем ителгәннәргә багышлап нәшер ителгән26 томны чыгаруда үзеннән зур өлеш кертте һәм кертә.Бу эш хәзердә дәвам итә.Ә. Ш. Садриев Татарстан Республикасы Хәтер китабы редакциясе әгъзасы. Ул үзе генә дә 10059 сугышчының язмышын ачыклаган.

Мәктәптә тарих укытудан тыш.1997 нче елда ул “Бөек Ватан сугышы музее”н оештыра һәм бүгенге көнгә кадәр аның белән җитәкчелек итә. 1997нче елның 16 нчы октябреннән 2016 нчы елның мартына кадәр музейда 44656 кеше-укучылар, ата- аналар, гомумән, төрле хезмәт вәкилләре булганнар.

Музейда Бөек Ватан сугышына ,халыклар дуслыгына, батырларга, Ватанны саклаучыларга багышлап төрле чаралар еш үткәрелә.Бу эшләрдә һәрвакыт башлап йөрүче,тынгысыз укытучыбыз–Әхәт абый.

Хәзерге вакытта,республикабызның башка районнарындагы кебек, Апас һәм Кайбыч төбәкләрендә төрле милләт вәкилләре бер гаилә булып гомер кичерәләр.Апас районында 22мең кеше яши.Шуның 86,2%-татарлар.6,9%- чувашлар,6,8%- руслар, 0,1%-башка милләтләр. Биредә 58 мәктәптә-3730 бала татар,рус, чуваш телләрендә белем ала.Халыкны тәрбияләүдә, аң- белем таратуда 31 китапханә,65 клуб эшли.Татар һәм рус телләрендә “Йолдыз”(“Зезда”) исемле газеталар данлы якташлар язмышын даими яктырту, буыннар эстафетасын дәвам итү буенча күркәм эш алып бара.Кайбыч районында 16,3 мең кеше яши.

Халыкның68%- татарлар, 29,9%-руслар, 2,1%- башка милләт вәкилләре тәшкил итә.41 мәктәптә 2614 бала белем ала. Бирердә46 клуб, 29 катапханә эшли.”Кайбыч таңнары”(“Кайбицкие зори”) газеталары басыла, халыкны тәрбияләүдә үзеннән зур өлеш кертә

## Йомгаклау.

Бу эшемдә ике районның күренекле шәхесләренбарладым. Киләчәктә дә бу эшемне дәвам итеп, яңадан – яңа исемнәр белән очрашуымны өмет итәм. Шәхесләребез – безнең горурлыгыбыз.Җыйналган материаллар, бай тарихыбызны өйрәнү – барлау юнәлешендә зур эшнең дәвамы булыр дип уйлыйм.Киләчәктә Тау ягы – Җәбәлстанның тарихи- мәдәни үткәненә багышланган яңа китаплар, кызыклы фәнни хезмәтләр туар.Анда инде төрле сәбәпләр аркасында бүгенге көндә исемнәре билгеле булмаган башка шәхесләребез  дә урын алыр.

**Кулланылган әдәбият.**

1) Х.Ф. Бәдретдинов “Кул буенда, кошлар тавында” . Казан, 2014 ел, 680 бит.

2) Х.А. Гайнуллин. “Апасын – гомер бишеген”. Казан, 2000 ел, 415 бит.

3) Х.А. Гайнуллин. “Тау ягының моңлы җырчысы”. Казан, 2006 ел, 207 бит.

4) А.Г. Сункишев. “Югалган авыллар. Апас, Кайбыч, Кама Тамагы”. Казан, 2011 ел, 195 бит.

5) А.Г. Сункишев. “Тылсымлы син, Тау ягы”. Казан, 2011 ел, 229 бит.

6) А.Г. Сункишев. “Апастовская историко-краеведческая энциклопедия”, том 3. Казань, 2014 год, 239 стр.

7) Р.А.Гарәфетдинов. “Кайбычым -Куанычым”.Кайбыч, 1998ел.320бит

8) М.Х. Хасанов һ.б. “Татарский энциклопедический словарь”. Казань, 1999 год.

9) А.А. Бурханов “Древности Предволжья”. Казань, 2003 год, 85 стр.